ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 221 от «14» 11 2022 г.

2021 елның 28 маендагы 119 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 21 мартындагы 211 номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда, дәүләт яки муниципаль органнар булып торучы операторлар тарафыннан каралган бурычларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау турында» карары, 2020 елның 30 апрелендәге Идел буе федераль округында Россия Федерациясе Президентының Тулы вәкаләтле вәкиле каршындагы Мәгълүматны яклау буенча Координацион Совет карарының 3.2 пунктын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына шикаять яки гариза белән мөрәҗәгать иткән гражданнарның һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең шәхси мәгълүматларын җыю, эшкәртү һәм яклау тәртибен билгеләү максатларында карар бирәм:

1. 2021 елның 28 маендагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының шәхси мәгълүматларын эшкәртү куркынычсызлыгы сәясәтен раслау турында»гы 119 номерлы карарга (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәешләрне кертергә:

1.1. 4.2 пунктның 4 абзацында «табыш алучы яки җаваплыкны үс өстенә алучы (поручитель) булып торырга» сүзләрен «табыш алучы яки җаваплыкны үс өстенә алучы (поручитель) булырга. Шәхси мәгълүматлар субъекты белән төзелә торган шартнамәдә балигъ булмаганнарның шәхси мәгълүматларын эшкәртү очракларын билгели торган шәхси мәгълүматлар субъектының хокукларын һәм ирекләрен чикләүче нигезләмәләр шулай ук шартнамә төзү сыйфатында шәхси мәгълүматлар субъектының гамәл кылмавына юл куя торган нигезләмәләр була алмый, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкаса каралмаган булса» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында шәхси мәгълүматларны эшкәртүне оештыру өчен җаваплы затка йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы А.П.Иванов

000235